# Казанда Муса Җәлил музее



**Адрес: 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., Горький ур., 17 йорт, 28 фатир.**

Музейга 1981 елда нигез салына. 1983 елның 15 феврлендә ачыла.1981 елдан алып Татарстан Республикасы Дәүләт берләштерелгән (Милли) музее филиалы.
Муса Җәлил (Җәлилов Муса Мостафа улы) (1906-1944) – татар шагыйре, әдәбият һәм җәмәгать эшлеклесе, ТАССР Язучылар берлеге рәисе (1939-1941).1944 елда Берлинда «Идел-Урал» легионында яшерен антифашистик эшчәнлек оештыруы өчен җәзалап үтерелә.Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты (ике исем дә үлгәннән соң бирелә).
1957 елда "Моабит дәфтәре" шигырьләр циклы өчен әдәби премия белән бүләкләнә.
Музей янәшәдәге ике фатирны били, берсе мемориаль.
Гомуми мәйдан – 126,2 м²
Музейга керә:
мемориаль фатир;
күргәзмәзалы;



М. Җәлилнең фотосурәте, 1941 ел



# Муса Җәлилнең эш бүлмәсе

# Торырга яраклы бүлмә





**М. Җәлилнең шәхси китапханәсе урнаштырылган китап шкафы.**

**Китапханәдә татар язучыларының, рус классикларының (А. С. Пушкин, М.Ю. Лермонтов, Н.А. Некрасов) әсәрләре, сүзлекләр, әдәби энциклопедия, музыка сәнгатен караган китаплар**



**Язу өстәле. М. Җәлил тарафыннан Мәскәүдә сатып алынган (1935 ел). Биредә шагыйрь 1939 елга кадәр яшәгән.**

**Өстәл өстендә кызы Чулпан белән төшкән фотосурәт**



М. Җәлил уйнаган мандолина. Шагыйрь тарафыннан 1934 елда сатып алынган.



**Фотоальбом.**

**М.Җәлил тарафыннан төзелгән. Шагыйрьнең шәхси, гаиләсе, дуслары фотосурәтләрен саклый**



Шагыйрьнең исән чагында ясалган беренче бюсты.

Һәвәскәр рәссам Г. Тимербулатов эше. 1936 ел



**Моабит дәфтәрләре. Моабит төрмәсе диварлары эчендә язылганнннар. Татарстан Республикасы Милли музее фондларында саклананалар. М. Җәлил музеенда һәр ел 15 февральдә «Асыл нөсхә көнендә» күрсәтеләләр.**





**Ленин премиясе лауреаты грамотасы. 1957 елда «Моабит дәфтәре» шигырьләр циклы өчен бирелә**




**Советлар Союзы Герое грамотасы. Бөек Ватан сугышында немец-фашист илбасарлары белән көрәшләрдә күрсәткән искиткеч ныклыгы һәм батырлыгы өчен 1956 елда лаек була**




**Шагыйрь М.Җәлил әсәрләренең чит ил басмалары**

Чыганак
http://www.tatar.museum.ru/Jalil/expos_tatkir.htm